Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Кирлегәч авыл җирлегенең
Кирлегәч торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 18 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

-Кирлегәч авылындагы зират территориясендә иске агачларны, куакларны кисү һәм үлән чабу;
- Кирлегәч авылы, Тукай урамы, 2а адресы буенча урнашкан зиратта каты көнкүреш калдыклары өчен 1 нче контейнер сатып алу
- Кирлегәч авылы урамнарын кардан чистарту
«РИЗА» «КАРШЫ».

соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 311 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 161.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 161 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлеге составына керүче Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

-Кирлегәч авылындагы зират территориясендә иске агачларны, куакларны кисү

һәм үлән чабу;
- Кирлегәч авылы, Тукай урамы, 2а адресы буенча урнашкан зиратта каты көнкүреш калдыклары өчен 1 нче контейнер сатып алу
- Кирлегәч авылы урамнарын кардан чистарту дигән карарын кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Керлигач авылы, Совет урамы, 33А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы С.Р.Сәлахова